**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2021 Балык Бистәсе штп. № 85пи

Социаль найм шартнамәсе буенча бирелә торак бина мәйданы нормасы һәм торак мәйданының хисап нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Торак бина мәйданының исәп нормасын гаиләнең бер әгъзасына торакның гомуми мәйданы 18 кв. метрдан да артык булмаган күләмдә билгеләргә. Шуннан чыгып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында торакка мохтаҗлар сыйфатында исәпкә алу максатларында гражданнарның гомуми торак мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе билгеләнә.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак бина белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, бер гражданинга социаль найм шартнамәсе буенча торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә торак урын бирү нормасын билгеләргә.

3.Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә

4.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Торак бина мәйданының исәп нормасын һәм бирү нормасын билгеләү турында» 2011 елның 28 июлендәге 281пи номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

5.Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары итеп йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов